| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| **РАСПОРЯЖЕНИЕ** | **БОЕРЫК** |

« 19 » феврать 2021 с. Тюлячи № 40

«Маленькие жемчужины» - «Нәни энҗеләр» конкурсы турында

Теләче муниципаль районында «Бөтендөнья татар конгрессы» иҗтимагый берләшмәләре Союзы җитәкчесенең 2020 елның 29 декабрендәге 2 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

1. «Маленькие жемчужины» - «Нәни энҗеләр» конкурсы Нигезләмәсен, кушымта нигезендә, расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«19» 02 2021 № 40
боерыгына кушымта

**«Нәни энҗеләр» район конкурсының**
**Нигезләмәсе**

Әлеге нигезләмә “Нәни энҗеләр” район конкурсын үткәрү тәртибен билгели.

## 1. Конкурсны оештыручылар

- Теләче муниципаль районы Татар Конгрессы район иҗтимагый оеш-масы;
- “Ак калфак " татар хатын-кызлары район иҗтимагый оешмасы;
- Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге;
- Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге.

Конкурсның Оештыру комитеты конкурста катнашучыларны сайлап алуны оештыра, жюри составын раслый, сайлап алу турын һәм конкурс финалын үткәрү урынын, сценарийны һәм программасын раслый. Жюри составына мәгариф, мәдәният эшлекләләре, Теләче районының массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре, җәмәгатьчелек вәкилләре керәчәк.

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

- үсеп килүче буынның ата-бабаларыбызның тарихи-мәдәни мирасы белән кызыксынуын арттыру, конкурста катнашучылар тарафыннан яңа белемнәр, күнекмәләр алу;
- гаиләгә, гаилә кыйммәтләренә аңлы мөнәсәбәт формалаштыру;
- балаларның иҗади мөмкинлекләрен үстерү;
- милли мәдәниятнең төрлелеген ачып бирә торган халык традицияләренә якынаю.

## 3. Конкурста катнашучылар

Конкурста Теләче муниципаль районында яшәүче 6 яшьтән алып 8 яшькә кадәрге балалар катнаша ала.

## 4. Бәйгене үткәрү тәртибе һәм шартлары

Конкурс 5 этаптан тора

*1 этап. Теркәлү.*

Конкурста катнашу өчен 2021 елның 25 февраленә кадәр анкета җибәрергә кирәк (анкета белән бергә 3 фотография җибәрелә (фотография күләме 3200х2700 га дан ким булмаган сыйфатта, шул исәптән үз халкының милли киемендә бер фотосурәт).

*2 этап.* Район сайлап алу туры 2021 елның 15 мартына кадәр үткәреләчәк (кайда үткәрү исемлеге өстәмә рәвештә игълан ителәчәк). Сайлап алу туры катнашучыларның үз презентациясе рәвешендә үткәрелә, ул үз эченә вокал, хореография яки башка иҗади номерларны ала. Шул ук вакытта коммуникатив күнекмәләр (үз-үзләрен тәкъдим итә белү), татар телендә аралашу күнекмәләрен, халык гореф-гадәтләрен, мәдәниятен белү исәпкә алына. Үз презентация вакыты - 3 минут.

*3 этап.* Икенче сайлап алу туры 21 мартка кәдәр узачак. Биредә “Нәни энҗеләр” конкурсының беренче этап җиңүчеләре конкурс этапларында катнашачак.

Конкурс этаплары катнашучыларның төрле якларын ачуга юнәлдереләчәк:

- кул эшләре бәйгесе;
- кулинария бәйгесе;
- спорт бәйгесе;
- интеллектуаль бәйге.

Бу чорда конкурсантлар белән профессиональ белгечләр эшләячәк: татар теле укытучылары, вокал, хореографлар, актерлык осталыгы буенча белгечләр, стилистлар, фотографлар һ.б.

*4 этап.* Конкурс финалы алдыннан әзерлек чоры.

Әзерлекчоры 2021 елның 22 мартыннан башланачак һәм конкурс финалына кадәр дәвам итәчәк.

*5 этап.* Конкурсның финалы.

Конкурсның финалы апрель аенда район мәдәният йортында узачак.

## 5. Приз фонды

Финалда катнашучыларның барысы да номинацияләр буенча дипломнар, иганәчеләрдән бүләкләр ала.

Бәйге номинацияләре:

“Сөйкемле кыз”, “Зыялы кыз”, “Ягымлы кыз”, “Талантлы кыз”, “Хуҗабикә”, “Тапкыр егет”, “Милли җанлы егет”, “Батыр егет”, “Баһадир егет”, “Җитез егет”.

Конкурс яңалыкларын ВКонтакте социаль челтәрендә Теләче муниципаль районы Татар Конгрессы төркемендә һәм Инстаграмм яңалыклар тасмасында карый аласыз.

Контактлар 89172297647 (Алиса Нурисламовна), 89393967641 (Зульфия Василовна), e-mail: ibragimova.1979@list.ru.

“Нәни энҗеләр” бәйгесенең оештыру комитеты составы

Оештыру комитеты рәисе::

| | | |
|---|---|---|
| Гыйниятуллин Д.С. | - | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары. |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Иксанов Д.С. | - | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге җитәкчесе; |
| Карпова Н.В. | - | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге җитәкчесе; |
| Дәүләтшина А.Н. | - | Теләче муниципаль районында «Бөтендөнья татар конгрессы” иҗтимагый берләшмәсе җитәкчесе; |
| Ибраһимова З.В. | - | Теләче муниципаль районында «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы җитәкчесе. |